Татарстан Республикасы Балык
Бистәсе муниципаль районы Яңа
Арыш авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 4**

Яңа Арыш авылы 14 апрель 2026 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Яңа Арыш авыл
җирлеге Советының 07.05.2018 елгы
5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү
турында «Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Яна Арыш авыл җирлеге муниципаль
хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары
күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне
һәм аларның тәртибен даими нигездә биләүче
затларга акчалата түләүләр билгеләү турында»
гамәлгә ашыру"

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләргә, муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга социаль гарантияләрне тәэмин итү, муниципаль хезмәткәрләргә, муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга хезмәт хакын тәртипкә китерү һәм камилләштерү максатларында муниципаль хезмәткәрләргә, муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга хезмәт хакы түләү системасы үзгәрүгә бәйле рәвештә «2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы нигезендә Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында», муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 26 статьясы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында»2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасында контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 28.03.2018 ел, №182 карарлары нигезендә, «дәүләт граждан хезмәтенә түләү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 29.12.2005 ел, №666 «Татарстан Республикасы дәүләт Вазыйфаларын биләүче затларга Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасыннан пенсиягә чыгуга бәйле бер мәртәбә бирелә торган акчалата бүләкләү түләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 10 июлендәге 353 номерлы Татарстан Республикасы хезмәткәренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә

бирелә торган бүләкләү турында, "Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасыннан пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә бирелә торган акчалата бүләкләү турында" 2025 елның 25 ноябрендәге 994 номерлы "Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында" «Муниципаль берәмлек Уставына таянып, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында "28.03.2018 ел, 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Яңа Арыш авыл җирлеге Советы КАРАР бирә:

1.Яңа Арыш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яна Арыш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 07.05.2018 елның 5 номерлы карарына (ред. 29.09.2020 №2; 14.10.2024 елдан №9; 04.02.2025 елдан №2) түбәндәге үзгәрешләр:

1.1) «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Яна Арыш авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга хезмәт өчен түләү күләмнәрен һәм шартларын» 1 нче кушымтада авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата хезмәт хакы күләмен 23 201 сум итеп билгеләргә;

1.2) «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Яңа Арыш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен» 2 кушымтасының 2 пунктында «15389,0» саннарын «16 928,0» саннарына алмаштырырга.

1.3) «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләр түләү күләмнәре һәм тәртибе» 5 нче кушымтаның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 3 нче абзац өстәргә: "Премия Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләре спартакиадасы кысаларында спорт төрләре буенча ярышларда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре җыелма командасы составында катнашкан муниципаль хезмәткәрләргә һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга түләнә.».

2. Әлеге карарның үз көчен 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерүен билгеләргә.

3. Яна Арыш авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Яңа Арыш авылы,Мәктәп урамы, 30 йорт, һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Яңа Арыш авыл жирлеге Башлыгы: Х.С.Зарипов